**Исполнительный комитет**
**Алешкин-Саплыкского**
**сельского поселения**
**Дрожжановского муниципального**
**района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Чүпрәле муниципаль районы**
**Алешкин-Саплык**
**авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**

**422478, Россия, Республика Татарстан, Дрожжановский район, с. Алешкин-Саплык, ул. Школьная, д.3а**
**тел. (84375) 37-5-35, 37-5-49, факс. 37-5-36**
**E-Mail: AlSap.Drz@tatar.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

с.Алешкин-Саплык

04 марта 2021 года №8

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» гы карарга үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 нче елның 08 нчы июнендәге 12 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» гы карарына (26.09.2018 ел №18, 17.12.2018 ел №28, 15.05.2019 ел №16, 16.09.2019 ел №20, 09.06.2020 ел №12 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (6 нчы кушымта):

а) 1.5 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган белешмә (Өземтә) астында түбәндәгеләр аңлана: хуҗалык кенәгәсеннән өземтә, йорт кенәгәсеннән архив өземтәсе, элекке яшәү урыныннан белешмә, көнкүреш характеристикасы.»;

б) 2.5 пунктының 2 нче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бирүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне раслаучы документ;

2) мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ, мөрәҗәгать итүче вәкиленең муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта (физик затларның законлы вәкилләреннән тыш);

3)гариза:

-документ формасында кәгазьдә (кушымта № 1);

- «Электрон имза турында» 06.04.2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә имзаланган электрон формада (тиешле мәгълүматларны интерактив формага кертү юлы белән тутырыла).;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүче булмаган затның персональ мәгълүматларын эшкәртү кирәк булса һәм әгәр федераль закон нигезендә мондый персональ мәгълүматларны эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән башкарыла ала икән, Муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән затның яисә аның законлы вәкиленең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгын алуны раслаучы документларны өстәмә рәвештә тапшыра. Рөхсәт алуны раслаучы документлар шул исәптән электрон документ формасында да тапшырылырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм кушып бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

- шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат);

- почта аша.

Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан Республика порталы аша электрон документлар рәвешендә тапшырылырга мөмкин (җибәрелгән).»;

в) 1 нче кушымтаны кушымта итеп бирелә торган редакциядә бәян итәргә;

г) 2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлегенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталына урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Алешкин-Саплык
авыл җирлеге башлыгы: П.Н.Артемьев

Кушымта№ 1

__________________________
(җирле үзидарә органы исеме
муниципаль берәмлек башлыгы)

________________________________________
(фамилия, имя, отчество)

__________________________________________

______________________________________,
(паспортные мәгълуматы)
адрес:______________________________
(белешмә, яшәү урыны буенча теркәлү)

________________________________________
Ышаныч буенча____________________
(Ф.И.О., ышаныч номеры)

________________________________________

________________________________________
(телефон)

## Белешмә (өземтәләр) бирү турында гариза

______________________________________________________________________________
(белешмә төрен күрсәтергә)

белешмә (Өземтә) бирүегезне сорыйм)
Түбәндәге адреска:__________________________________________________
Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:
1. _________________________________________________________________________
2. _________________________________________________________________________
3. __________________________________________________________________________

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында түбәндәге ысул белән хәбәр итүегезне сорыйм ______________________________________

____________________/_____________________/_________________________________
(дата) (подпись) (Ф.И.О.)